ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
БАВЛИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАУЛЫ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

24.09.2020 ел. Баулы шәһәре №188

Баулы муниципаль районы башкарма комитетының 2017 елның 11 декабрендәге 504 номерлы «Кулланучылар кооперациясе оешмаларының Баулы муниципаль районы үзәгеннән - Баулы шәһәреннән 11 километр ераклыкта урнашкан Баулы муниципаль районының ерак һәм халкы аз санлы торак авыл пунктларына беренче чиратта кирәкле товарларны китерү белән бәйле чыгымнары өлешен каплауга субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» карарына (2018 елның 19 июнендәге 238 номерлы, 01.11.2019 №305 номерлы карарлар белән кертелгән үзгәрешләр белән) үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2017 елның 20 декабрендәге 887 номерлы “Татарстан Республикасының район үзәкләреннән 11 километр ераклыкта урнашкан Татарстан Республикасының ерак һәм халкы аз санлы торак авыл пунктларына беренче чиратта кирәкле товарларны китерүгә бәйле кулланучылар кооперациясе оешмаларының чыгымнарын өлешчә каплауга Татарстан Республикасы бюджетыннан Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре бюджетларына башка бюджетара трансфертлар бирү тәртибен раслау турында» карарына үзгәрешләр кертү хакында” карары нигезендә Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы башкарма комитеты

КАРАР ИТӘ:

1. Баулы муниципаль районы башкарма комитетының 2017 елның 11 декабрендәге 504 номерлы «Кулланучылар кооперациясе оешмаларының Баулы муниципаль районы үзәгеннән - Баулы шәһәреннән 11 километр ераклыкта урнашкан Баулы муниципаль районының ерак һәм халкы аз санлы торак авыл пунктларына беренче чиратта кирәкле товарларны китерү белән бәйле чыгымнары өлешен каплауга

субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» карарына (2018 елның 19 июнендәге 238 номерлы, 01.11.2019 №305 номерлы карарлар белән кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

карар исемендә һәм алга таба текст буенча «ерак һәм халкы аз санлы авыл пунктлары» сүзләрен «авыл торак пунктлары» сүзләренә алмаштырырга.

2. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Баулы муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесенең икътисадый үсеш буенча урынбасарына йөкләргә.

Баулы муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе И.И. Гозәеров